# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасының Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына салым ташламалары бирү турында

1 статья. Хәрәбә хәлендәге торакларны бетерү программасын гамәлгә ашыру һәм хәрәбә хәлендәге кварталларны үзгәртеп кору чорына Татарстан Республикасының Бюджеттан тыш дәүләт торак фондын Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларга пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегеннән, Татарстан Республикасы Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондыннан, Россия Федерациясенең җәмгыяви иминләштерү фондының Татарстан тәбәге бүлегеннән һәм мәҗбүри медицина иминлеге кертемнәреннән гайре, барлык төр салымнарны түләүдән, бюджеттан тыш дәүләт фондларына түләүләрдән азат итәргә.

2 статья. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 28 марты
N 487